ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 октября 2022г. № 5361

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик тарифларны раслау турында» 2021 елның 23 апрелендәге 2859 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик тарифларны раслау турында» 2021 елның 23 апрелендәге 2859 номерлы карары кушымтасына, 1.1, 2 пунктларны кушымтада каралган редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 7 октябрендәге
5361 номерлы карарына
кушымта

«Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» МАУ
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтләрнең һәм (яки) түләүле муниципаль хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәя, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Мунчаларда юыну хезмәтләре | | |
| 1.1 | Мунчаларның гомуми бүлегендә юыну хезмәтләре: | | |
| | Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар, фашист концлагерьларының балигъ булмаган тоткыннары, «Блокадаланган Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, Социалистик хезмәт Геройлары, СССР Геройлары (документ – пенсия таныклыгы күрсәткәндә) | сәгать (1 сәгать 45 минут) | бушлай |
| | Бөек Ватан сугышы инвалидлары (документ – пенсия таныклыгы күрсәткәндә) | | |
| | диализда торучы, сәламәтлекләре буенча инвалидлар (документ күрсәткәндә) | | |
| | 7 яшькә кадәрге балалар (документ – туу турында таныклык күрсәткәндә) | | |
| | 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда кимендә алты ай тылда эшләгән (СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорын кертмичә) яисә Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затлар (документ күрсәткәндә) | | 108,50 |
| | һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннары (документ күрсәткәндә) | | |
| | барлык категория пенсионерлар | | 185,00 |
| | гражданнарның башка категорияләре | | 250,00 |
| 2 | Бассейннан файдалану хезмәтләре: | | |
| | барлык категория гражданннар өчен | сәгать (45 минут) | 150,00 |
| | барлык категория пенсионерлар | | 115,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева